РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» март 2023 ел г. Альметьевск № 652

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының «Мәктәпкәчә белем
бирү программасын гамәлгә ашыручы
мәгариф учреждениеләренә йөрүче
балалары булган гражданнарга социаль
ярдәм чаралары күрсәтү турында»
2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы
карарына үзгәреш кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 04.02.2023 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 26 сентябрендәге 3662 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 02 октябрендәге 3737 номерлы, 2013 елның 04 октябрендәге 3757 номерлы, 2014 елның 14 мартындагы 726 номерлы, 2015 елның 9 ноябрендәге 1290 номерлы, 2016 елның 31 маендагы 1147 номерлы, 05 февраль 2018 елның 11 сентябрендәге 1655 номерлы, 2021 елның 04 февралендәге 166 номерлы карарлары кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 нче кушымтаның 1 бүлегенең 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Гаиләнең җан башына уртача керем компенсация алуга хокукны билгеләгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында" 2019 елның 03 декабрендәге 1095 номерлы карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.

Балага түләү билгеләгәндә гаиләнең җан башына уртача кереме гаилә әгъзаларының бала өчен айлык пособие билгеләү турында гариза бирү айларына кадәрге соңгы 12 календарь айда булган керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып

Зак. № 305-2000

чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов